МИНИСТЕРСТВО СПОРТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.10.2020 г.Казань № 305

Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә квалификация категориясе бирү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2007 елның 4 декабреннән «Россия Федерациясендә физик тәрбия һәм спорт турында» 329-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсе, Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2019 елның 19 декабреннән «Физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә башка белгечләргә квалификация категорияләрен бирү тәртибен һәм физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә башка белгечләргә квалификация категорияләр бирүнең квалификация таләпләрен раслау турында» 1076 номерлы, 2020 елның 19 мартыннан «Тренерларга квалификация категорияләрен бирү тәртибен һәм тренерларга квалификация категорияләре бирүгә квалификация таләпләрен раслау турында» 224 номерлы боерыклары нигезендә

**боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлә торган Административ регламентын расларга.
2. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүне министрның беренче урынбасары Х.Х. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
15.10.2020 № 305

боерыгы белән расланды

## Татарстан Республикасы территориясендә физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә тренерларга, белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламенты

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. гариза бирүчеләр:

- спорт әзерлеген гамәлгә ашыра торган тренер, өлкән тренер, адаптив физик тәрбия буенча укытучы-тренер, адаптив физик тәрбия буенча өлкән укытучы-тренер (алга таба – тренерлар);
- инструктор-методист, өлкән инструктор-методист, адаптив физик тәрбия буенча инструктор-методист, адаптив физик тәрбия буенча өлкән инструктор-методист (алга таба – физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә белгечләр).

1.3. Үз эшчәнлекләрен башкарма хакимиятнең федераль органнары гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырмый торган оешмаларда тормышка ашыра торган тренерларга һәм физик тәрбия һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә югары һәм беренче квалификация категорияләрен бирү буенча дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасы спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) күрсәтә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан шәһәре, Петербург урамы, 12 йорт.

Министрлыкның эш тәртибе: шимбә һәм якшәмбедән тыш һәр көнне, 9:00 дан 18:00 кадәр, төшке аш вакыты 12:30 дан 13:30 кадәр.

Җәмәгать транспортында «Божра» тукталышына кадәр:

- 1, 91, 35а, 37, 29, 90, 71, 47 нче номерлы автобуслар;
- 2, 7, 17, 6, 8, 12 нче номерлы троллейбуслар белән,
- метро белән «Тукай мәйданы» станциясенә кадәр килергә.

Бинага керү үткәрү кәгазе һәм (яки) шәхесне раслый торган документ буенча.

1.3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм үтәү барышы турында хәбәр бирү министрлыкның Спорт резервын әзерләү секторы (алга таба – Сектор) тарафыннан (843) 222-81-72 телефоны аша тормышка ашырыла.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган «Татарстан Республикасы рәсми порталы» рәсми сайты адресы (алга таба – министрлыкның рәсми сайты һәм «Интернет» челтәре): http://minsport.tatarstan.ru/.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Секторның урнашкан урыны һәм аның эш графигы турындагы мәгълүматны түбәндәге юллар белән алырга мөмкин:

1) Гариза бирүчеләр белән эш өчен Министрлык биналарында урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст формасындагы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аша.

2) «Интернет» челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://minsport.tatarstan.ru/);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләт һәм һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләре) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итү ысулы белән (телефон буенча яки шәхсән);

4) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать аша (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

1.3.5. Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә өчен телефоннар, эш тәртибе, рәсми сайт, шулай ук электрон почта адресы турында мәгълүмат Сектор белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмати системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында урнаштырыла.

Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү өчен биналарындагы мәгълүмати стендларда һәм Министрлыкның рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (подпунктларында) күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүматны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актлар реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Квалификация категориясе 4 ел вакытка билгеләнә. Квалификация категориясенең гамәлдә булу вакыты озайтылмый.

1.6. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм аларның билгеләмәләре кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – КФҮ) – 2010 елның 27 июленнән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ нчы номерлы Федераль законы (алга таба – 210 Фз номерлы федераль закон) таләпләренә җавап бирә торган дәүләт яки муниципаль учреждениесе оештыру-хокукый формасында төзелгән һәм «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр, шул исәптән электрон формада да күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтә урнашкан эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабреннән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 1376 нчы номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәсенең 34 пунктына туры китереп, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр һәм авыл җирлекләрендә булдырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль аерымлашкан структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) кертелгән белешмәләрнең шулар нигезендә кертелгән мәгълүматларның документлардагы белешмәләргә туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

Мөрәҗәгать итүче вәкиле – үз вәкаләтләре нигезендә яисә законда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә Мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат.

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигән чакта дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос күз алдында тотыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсенең1 пункты).

Гаризалар формалары Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2019 елның 19 декабрендәге 1076 номерлы боерыгы белән расланган Физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә башка белгечләр квалификация категорияләрен бирү тәртибенә һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2020 елның 19 мартындагы 224 номерлы боерыгы белән расланган Тренерлар квалификация категорияләрен бирү тәртибенә кушымталарда китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтү яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1 Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә квалификация категорияләре бирү | 2007 елның 4 декабреннән ФЗ «Россия Федерацисендә физик тәрбия һәм спорт турында» (алга таба – 329-ФЗ номерлы Федераль закон); 329-ФЗ номерлы Федераль закон; 2020 елның 19 мартыннан Россия Федерациясе Спорт министрлыгы 224 нче номерлы боерыгы белән расланган Тренерларның квалифи-кация категорияләрен бирү тәртибе (алга таба – 224 номерлы Тәртип), 2019 елның 19 декабреннән Россия Федерациясе Спорт министрлыгы 1076 нче номерлы боерыгы белән расланган Физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә башка белгечләргә квалификация |

| | | |
|---|---|---|
| | | категорияләрен бирү тәртибе (алга таба – 1076 номерлы Тәртип); Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июленнән карары белән рсланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы турында Нигезләмә (алга таба – Министрлык турында Нигезләмә) |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы | 329-ФЗ номерлы Федераль законының 22 маддәсе 14 өлеше 3 подпункты; Министрлык турында Нигезләмәнең 3.3.1 подпункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен сурәтләү | Беренче яки югары квалификация категорисен бирү турында карар<br>Мөрәҗәгать итүчеләргә беренче яки югары квалификация категориясен бирүдән баш тарту | 224 номерлы Тәртипнең 25, 26 пунктлары;<br>1076 номерлы Тәртипнең 23, 24 пунктлары |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген истә тотып, вакыты; әгәр Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөм-кинлеге каралган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып | Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гаризаны һәм документларны теркәгән көннән алып 80 календарь көне тәшкил итә.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны, гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын (почта аша, электрон адреска) кулланып, дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә җибәрелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | 224 номерлы Тәртипнең 19, 23, 25, 26 пунктлары;<br>1076 номерлы Тәртипнең 18, 21, 23, 24 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган до-кументларны бирү (юллау) вакыты | | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар белән каралган, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарур һәм мәҗбүри булган хезмәтләр өчен мөрәҗәгать итүче бирергә тиешле мәҗбүри документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу, шул исәптән электрон формада да, ысуллары, аларны бирү тәртибе | Квалификация категориясен бирү өчен түбәндәгеләрне бирергә кирәк:<br>а) 1076 номерлы Тәртипкә һәм 224 номерлы Тәртипкә кушымталарда китерелгән формалар буенча квалификация категориясе бирү турында гариза;<br>б) Россия Федерациясе гражданины паспортының икенче һәм өченче битләренең, шулай ук мөрәҗәгать итүченең тору урыны турында мәгълүматлар булган битләренең күчермәләре;<br>в) җитәкченең имзасы һәм оешма мөһере (булганда) белән расланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66[1] маддәсе нигезендә хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;<br>г) квалификация категориясе бирүне раслый торган документ күчермәсе (булганда);<br>д) спорт әзерлеген узучы затның физкультура-спорт оешмасына керүен дәлилли торган җитәкче имзасы һәм оешма мөһере белән (булган очракта) расланган документ күчермәсе, (тренерга квалификация категориясе бирү өчен);<br>е) спорт әзерлеге узучы затны тренерның тренировка төркеменә кабул итү турындагы боерыктан оешма җитәкчесе имзасы һәм мөһере белән (булган очракта) расланган өземтә (тренерга квалификация категориясен бирү өчен);<br>ж) баш хөкемдарлар коллегиясе рәисе, рәсми спорт чарасының баш хөкемдары кул куйган рәсми спорт чарасы беркетмәсенең күчермәсе яисә беркетмәсеннән өземтә (тренерга квалификация категориясен бирү өчен); | 224 номерлы Тәртипнең 13, 14, 15 пунктлары;<br>1076 номерлы Тәртипнең 12, 13, 14 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | з) спорт әзерлеге узучы затка спорт исеме һәм (яки) спорт разряды бирү турындагы боерыкның җитәкче имзасы һәм оешма мөһере белән (булган очракта) расланган күчермәсе (тренерга квалификация категориясе бирү өчен);<br>и) спорт әзерлеге узучы затны спорт әзерлегенең киләсе этабына күчерү турындагы боерыктан җитәкче имзасы һәм оешма мөһере белән (булган очракта) расланган өземтә (тренерга квалификация категориясе бирү өчен);<br>к) спорт әзерлеге узучы затның Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы спорт җыелма командасына кандидатлар исемлегенә кертелүен раслый торган боерык актының күчермәсе (тренерга квалификация категориясе бирү өчен);<br>л) спорт әзерлеге узучы затның тикшерү-күчерү нормативларын тапшыруы нәтиҗәләре белән җитәкченең имзасы һәм оешма мөһере белән (булганда) расланган беркетмә күчермәсе (тренерга квалификация категорияле бирү өчен);<br>м) мөрәҗәгать итүченең семинарларда, конференцияләрдә, ачык дәресләрдә, мастер-классларда һәм башка фәнни-гамәли чараларда катнашуы турында әлеге чараларны оештыручылар биргән документ күчермәсе (булганда);<br>н) мөрәҗәгать итүченең һөнәри эшчәнлеге чорында мактаулы спорт исемнәре һәм (яки) ведомство бүләкләре бирүне раслаучы документ күчермәсе;<br>о) методик эшкәртмәләр (публикацияләр) күчермәләре (булганда).<br>Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза һәм аңа теркәп бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән бирелергә (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән үз вәкаләтләре нигезендә я ышаныч кәгазе буенча эш итүче зат аша);<br>почта аша.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон документ рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәк булган һәм Гариза бирүче бирергә хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләрнең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә дә, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Әлеге категориягә туры килергә мөмкин булган документлар бирү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мәҗбүри булган документларны кабул итүдән баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | 1. Гаризаны 1076 нчы номерлы Тәртипкә һәм 224 номерлы Тәртипкә кушымталарда китерелгән формаларга туры килми торган формада бирү.<br>2. Гариза бирүче тарафыннан тапшырыла торган документларда нинди дә булса мәгълүматларның булмавы яки дөрес булмаган мәгълүматларның булуы.<br>3. Әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган комплектын бирү.<br>4. Әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затка дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү.<br>5. Әлеге вазыйфа буенча икенче квалификация категориясен билгеләгәннән соң бер ел да үтмичә беренче яки югары квалификация категориясен бирү турында гариза бирү (моңа кадәр тренер-укытучы вазыйфасы буенча югары яки беренче квалификация категорияле тренерлар бирелгән очраклардан тыш, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2014 елның 7 апреленнән 276 номерлы боерыгы белән расланган белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү тәртибе нигезендә, беренче яки югары категорияне бирүгә гаризалар бирелә). | 224 номерлы Тәртипнең 3, 13 пунктлары;<br>1076 номерлы Тәртипнең 12 пункты |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә аңардан баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен сәбәпләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен сәбәпләр каралмаган. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төр түләүнең тәртибе, күләме һәм алу өчен сәбәпләр | Дәүләт хезмәте бушлай нигездә күрсәтелә.. | |
| 210. Дәүләт хезмәтен күрсәтү | Зарур һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, түләү алу тәртибе, күләме һәм сәбәпләре | Зарур һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма күрсәтә торган хезмәтне күрсәтү турында запрос биргән вакытта һәм шундый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маеннан «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 601 номерлы Указы |
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма күрсәтә торган хезмәт күрсәтүне сорап, шул исәптән электрон формада да, | Гариза кергән көн дәвамында.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килгән көнне теркәлә. | |

| | | |
|---|---|---|
| соравын (запрос) теркәү вакыты һәм тәртибе | | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең көтү залына дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап гариза тутыру урыннарына, һәрбер дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларның тулы исемлеге һәм аларны тутыру үрнәкләре белән мәгълүмати стендларга, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиялы мәгълүмати стендлар урнаштыруга һәм тышкы күренешенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасының законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуларын тәэмин итүгә таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәк булган мебель, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Визуаль, текстлы һәм мультимедиале мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.<br>Инвалидларның (кресло-коляскалар һәм озатып йөрүче этләрдән файдалана торган инвалидларны да кертеп) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына комачаулыкларсыз килүен оештыру максатларында аларга түбәндәгеләр тәэмин ителә:<br>бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү өчен шартлар;<br>мөстәкыйль яки хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр ярдәмендә Министрлык территориясе буйлап хәрәкәт итү, Министрлык бинасы һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу мөмкинлеге;<br>транспорт чарасына утыру һәм аннан бинага керү алдыннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәме белән;<br>күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт функцияләре бозылган инвалидларны озата бару һәм аларның мөстәкыйль йөрүләре һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларның объектларга һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итү өчен кирәкле булган җиһазлар һәм мәгълүмат чыганакларын, аларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, тиешле итеп урнаштыру; | 1995 елның 24 ноябреннән «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яктан яклау турында» 181-ФЗ номерлы федераль закон;<br>2015 елның 24 августыннан Россия Федерациясе Спорт министрлыгының «Физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә инвалидлар өчен объектларның һәм күрсәтелә торган хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булу шартларын тәэмин итү, шулай ук инвалидларга шул вакытта кирәк булган ярдәмне күрсәтү тәртибен раслау турында» 825 номерлы боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельеф-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә рөхсәт бирү;<br>бинага, махсус укытуны раслаучы документы булганда, озатып йөрүче этне кертү;<br>хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан башка затлар белән беррәттән хезмәт алуга һәм объектлардан файдалануга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда инвалидларга кирәкле башка ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларда организм функцияләренең нык бозылулары һәм тормыш эшчәнлеге чикләүләре булуын исәпкә алып, бинаны физик тәрбия һәм спорт белән шөгыльләнү өчен махсус спорт инвентаре һәм җиһазлар белән тәэмин итү;<br>инвалидларга, тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, махсуслаштырылган төркемнәрдә физик тәрбия һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыруны тәэмин итү;<br>инвалидлар белән физик тәрбия һәм спорт дәресләрен үткәрү өчен әзерләнгән хезмәткәрләр булу.<br>Таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә кулланыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>бүлек биналарының җәмәгать транспортыннан файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтелгән вакытта вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-телекоммуникацияле технологияләрне файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте алуның дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә 210 – ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] маддәсендә каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәте күрсәтүләрнең күпфункцияле үзәкләрендә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәте күрсәтүне сорау юлы белән), мөрәҗәгать итүче сайлавы буенча башкарма комитетның теләсә нинди территориаль бүлекчәсендә (экстерриториаль принцип) алу яки алмау мөмкинлеге | документларны кабул итә торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү юллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә, министрлыкның рәсми сайтында тулы мәгълүмат булуы;<br>инвалидларга аларга башкалар белән бертигез хезмәт алырга комачаулый торган барьерларны җиңүдә ярдәм итү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>гаризаларны кабул итү һәм карау вакытын саклау;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен алу вакытын саклау;<br>дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан җибәрелгән Административ регламентны бозуга карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булмау;<br>гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән үзара тәэсир итешү саны:<br>турыдан-туры гариза бирү – бердән артмаска тиеш (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>гаризаны һәм документларны почта аша яисә электрон рәвештә юллаганда – бердән артмаска тиеш (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Гариза бирүче белән үзара тәэсир хезмәттәшлек дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат Министрлыкка гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирү) күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннары аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче http://minsport.tatarstan.ru сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең | |

| | | |
|---|---|---|
| | бердәм порталында, татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында алырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип һәм комплекслы сорау буенча дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |
| 2.16.Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцибы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә алып (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелми.<br>Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру тәртибе турында «Интернет» челтәре аша консультация үткәрү мөмкинлеге бар. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрның) составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формадагы административ процедураларны (гамәлләрне) башкару үзенчәлекләре

3.1. Татарстан Республикасы территориясендә физик тәрбия һәм спорт өлкәсендә тренерларга, белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – квалификация категориясе) үз эченә түбәндәге процедураларны ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, ярдәм күрсәтүне күздә тоткан консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) кергән документларны карау һәм документларны Министрлыкның квалификация категорияләрен бирү комиссиясенә (алга таба – Комиссия) тапшыру турында карар кабул итү;

4) мөрәҗәгать итүчегә квалификация категориясен бирү (бирмәү) турында Министрлыкның карар кабул итүе;

5) техник хаталарны (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик хаталар) төзәтү.

3.2. Гариза язучыга консультация бирү, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документларны тутыру өлешендә ярдәм күрсәтү.

Гариза бирүче Секторга шәхсән, телефон аша һәм (яисә) (шул исәптән электрон почта аша) дәүләт хезмәтләрен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Сектор белгече гариза бирүчегә, шул исәптән гариза формасы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүен алу өчен башка мәсьәләләр буенча да консультация үткәрә. Кирәк булганда, Сектор белгече гариза бирүчегә шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнеп куела торган процедура Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган гаризаны рәсмиләштерү һәм документларның билгеләнгән комплекты өлешендә консультация бирү, ярдәм күрсәтү.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче (аның вәкиле) дәүләт хезмәте күрсәтү турында әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән кәгазьдәге гаризаны шәхсән үзе, электрон формада Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә почта аша хат белән Секторга тапшыра (юллый).

3.3.2. Сектор белгече мөрәҗәгать итүче тапшыра торган гаризаны кабул итүне, әлеге Административ регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булугы тишерүне гамәлгә ашыра.

Әлеге Административ регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булган очракта, Сектор белгече гариза алудан баш тарта.

Әлеге Административ регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булмаган очракта, Сектор белгече:

документларны терки;

гаризаның кабул итү датасы турындагы тамга белән күчермәсен тапшыра (шәхсән гариза тапшырганда);

Әлеге пункт билгеләгән Процедура гариза бүирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза кабул итүдән баш тарткан очракта гариза бирүчегә гариза кире кайтарыла, баш тарту өчен сәбәпләр булмаган очракта - теркәлгән гариза.

4. Кергән документларны карау һәм документларны Комиссиягә тапшыру турында карар кабул итү.

Квалификация категорияләрен бирүне Комиссия Министрлык боерыгы белән расланган Комиссия турындагы Нигезләмә нигезендә үткәрә.

3.4.1. Сектор белгече Комиссия карау өчен гариза бирүчеләр исемлеген формалаштыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, алдагы процедураны тәмамлаганнан соң, бер календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: формалаштырылган исемлек.

3.4.2. Документларны комиссиягә карау өчен тапшыру турындагы карарны раслау өчен Сектор белгече «Һөнәри эшчәнлек нәтиҗәләрен квалификация таләпләренә туры китерүгә эксперт бәяләве үткәрү турында» Министрлык боерыгы проектын формалаштыра һәм боерык проектын килештерүгә министрның беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гаризаларны теркәү тәмамланганнан соң дүрт календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына килештерүгә юлланган боерык проекты.

3.4.3. Министрның беренче урынбасары боерык проектын карый, килештерә һәм раслау өчен министрга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрга раслауга юлланган боерык проекты.

3.4.4. Министр эксперт бәяләвен үткәрү турында боерыкны раслый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган боерык.

3.5. Министрлыкның мөрәҗәгать итүчегә квалификация категориясен бирү (бирмәү) турында Карар кабул итүе

3.5.1. Әлеге Регламентның 3.4 пунктында каралган процедуралар тәмамланганнан соң 53 календарь көне эчендә Комиссия гариза бирүчеләрнең һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәләренә эксперт бәяләве үткәрүне оештыра.

Мөрәҗәгать итүченең квалификация таләпләренә туры килүе (туры килмәве) турында Комиссия карары утырыш уздырылган көннән 7 календарь көн эчендә Комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә Министрлык мөрәҗәгать итүчегә квалификация категориясен бирү (бирмәү) турында карар кабул итә.

Сектор белгече министрлыкның «Беренче яки югары квалификация категориясен бирү турында» боерыгы проектын яки квалификация категориясен бирмәү турында хезмәт язуы проектын формалаштыра һәм министрның беренче урынбасарына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар беркетмә рәсмиләштерелгән көннән сигез календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына килештерүгә юлланган боерык проекты яки квлификация категориясен бирмәү турында хезмәт язмасы проекты

3.5.2. Министрның беренче урынбасары боерык проектын яки квалификация категориясен бирмәү турында хезмәт язуы проектын карый, килештерә һәм раслауга министрга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң ике календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министрга раслауга җибәрелгән боерык проекты яки квалификация категориясен бирмәү турында хезмәт язуы проекты.

3.5.3. Министр «Беренче яки югары квалификация категориясен бирү турында» боерыкны раслый яки килештерелгән хезмәт язмасына тиешле резолюция сала һәм белгечкә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган боерык.

3.5.4. Белгеч гариза бирүчегә язмача рәвештә Министрлыкның беренче яки югары квалификация категориясен бирү турында боерыгын яисә квалификация категориясен бирмәү турында министр резолюциясен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә «Беренче яки югары квалификация категориясен бирү турында» министр боерыгы, министрның мөрәҗәгать итүчегә тиешле квалификация категориясен бирмәү турындагы хезмәт язмасында резолюциясе.

3.6. Техник хаталарны төзәтү.

3.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта мөрәҗәгать итүче Секторга түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән форма буенча техник хатаны төзәтү турында гариза;

Мөрәҗәгать итүчегә техник хата булган дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе буларак бирелгән документ.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша, яисә электрон почта аша, яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша тапшыра.

3.6.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы Сектор белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, бергә бирелгән документлар белән гаризаны терки.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.6.3. Сектор белгече документларны карый һәм хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки мөрәҗәгать итүчегә почта аша (электрон почта аша) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү үз эченә Гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуларны ачыклау һәм юкка чыгаруны, шикаятьләр карауны, тикшерүләр уздыру, карарлар кабул итү һәм Гариза бирүчеләр мөрәҗәгатьләренә җавап әзерләүне, Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамьсезлекләренә) карарлар әзерләүне ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшерү формалары булып:

эш башкаруны алып бару;

документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүе;

документларны кабул итү вакытларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәтен күрсәткән чакта нәтиҗәләрне бирү вакытларын һәм тәртибен үтәү тора.

Тикшерүләр үткәрүнең кабатланып торуы планлы (эш планы нигезендә уздырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең аерым мөрәҗәгате буенча) характерда була.

Әлеге Регламентның 3 бүлегендә билгеләнгән административ процедураларның үтәлешен тикшереп тору нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча белешмә тапшырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеген агымдагы тикшерү министрның беренче урынбасары тарафыннан башкарыла.

4.3. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланганда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы гаепле дип табылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.3. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерү Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләр (шикаятьләр) карауның судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат бирү юлы белән тормышка ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә Министрлыкның дәүләт гражданлык хезмәткәренең гамәлләренә (гамьсезлегенә) карата судка кадәр – Министрлыкка дәгъва бирергә хокуклы.

Министр кабул иткән дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле карарларга шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Гариза бирүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында Гариза бирүченең гаризасын теркәү вакытын бозган очракта;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытын бозганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар яисә мәгълүматларны, яки күздә тотылмаган гамәлләрне тормышка ашыруны таләп иткәндә;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүне кире каккан чакта;

5) әгәр кире кагу өчен нигезләмәләр федераль законнар, аларга бәйле рәвештә кабул ителгән башка Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне кире какканда;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү кертүне таләп иткән очракта;

7) дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлык, аның дәүләт хезмәте күрсәтә торган вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар яисә хәреф хаталарын төзәтүдән баш тарткан яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозган чагында;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яисә тәртибен бозганда;

9) федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатканда;

10) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәткәндә кирәк булган документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда, яисә 210-ФЗ Федераль законының 7 маддәсе

1 өлеше 4 пункты белән каралган очраклардан тыш дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәк булган документлар яки мәгълүматның булмавы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән мәгълүматны таләп итү.

5.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан http://minsport.tatarstan.ru файдаланып, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең (функцияләре) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчедән шәхси кабул итү вакытында алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгән көннән алып 15 эш көне дәвамында. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт күрсәтүче органның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документлар кабул итүдән яки җибәрелгән хаталар һәм хәреф хаталарын төзәтүдән баш тарту буенча, яисә шундый төр төзәтүләрне кертүнең билгеләнгән вакытларын бозуга карата шикаять язган очракта – аны теркәгән көннән башлап биш эш көне дәвамында. Шикаятьне карау вакыты – аны теркәгәннән соң 15 эш көне дәвамында.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

1) карарлары яисә гамәлләренә (гамьсезлегенә) шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме соңгысы – булган очракта), тору урыны турында мәгълүмат, гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта (булган очракта) адресы (адреслары) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамьсезлеге) турында мәгълүмат;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның вазыйфаи заты яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамьсезлеге) белән килешмәү өчен нигез булып торган дәлилләр.

5.5. Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчерелмәләре тәкъдим ителергә мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) Шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталар һәм хәреф хаталарын төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив

хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган акчаларны кире кайтару формасында;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 подпунктларында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соңгы көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә язмача рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьне канәгатьләндерерлек дип тапкан очракта, гариза бирүчегә әзерләнгән җавапта дәүләт хезмәтен күрсәткәндә җибәрелгән бозуларны кичекмәстән юкка чыгару максатында Министрлык тарафыннан тормышка ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук җибәрелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм гариза бирүчегә алга таба дәүләт хезмәтен алу өчен кирәк мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаятьне канәгатьләндерерлек түгел дип тапкан очракта, гариза бирүчегә җавапта әлеге карарны кабул итү буенча дәлилләнгән аңлатма, шулай ук кабул ителгән карар буенча шикаять язу тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу составы яисә җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләр карау буенча вәкаләтләре булган вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

тәкъдим ителә торган форма

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ___________________________________________________________________________

(хезмәт атамасы)

Язылган:___________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:_________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта ул карарны::

электрон документ рәвешендә E-mail адресына:_______;

расланган копия рәвешендә кәгазьдә почта аша түбәндәге адрес буенча: _____________________________________________________________________җибәрүне сорыйм.

Дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, ачыклау (яңарту, үзгәртү), куллану, තарату (шул исәптән тапшыру), персональ мәгълүматларны шәхси үзенчәлекләрне юкка чыгару, блоклау, юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләр, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, кылуга. алар нигезендә Министрлык тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп, үз ризалыгымны, шулай ук мин тәкъдим итә торган затның ризалыгын раслыйм.

Минем шәхесемә һәм мин тәкъдим иткән затка караган, гаризага кертелгән мәгълүматларның дөреслеген раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән

таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытка әлеге документлар гамәлдә, һәм андагы мәгълүматлар хак.

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша: _________________________. сораштыруда катнашырга ризалык бирәм.

_________ _____________ ( _________________)

(дата) (имза) (Ф.И.Аи.)

Татарстан Республикасы территориясендә тренерларга, физик тәрбия һәм спорт өлкәсендәге белгечләргә квалификация категорияләре бирү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

Дәүләт хезмәте күрсәтү һәм аның үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 222-81-01(02) | Vladimir.Leonov@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары | 222-81-03 | Halil.Shayhutdinov@tatar.ru |
| Спорт резервы әзерләү секторы мөдире | 222-81-72 | Natalya.Alkaeva@tatar.ru |

Аппарат Кабинета Министров Республики Татарстан

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше формалаштыру бүлеге башлыгы | 264-77-84 | Guzel.Shakirova@tatar.ru |